# Тарихи мәчетләрнең берсендә

***Гасырлар кичеп, бүгенге көннәргә кадәр сакланып калган тарихи мәчетләр аз булса да, бар алар безнең татар авылларында. Яндавишчада, Кече Рбишчада, Камкада, Красный Островта, Ишавылда, Бозлауда, мәсәлән. Соңгысында тарихи мәчет XIX гасыр башында Якуб исемле сәүдәгәр акчасына төзелгән. Совет чорында мәчет бинасында иген амбары урнашкан. Халык фикере буенча, бу бинада амбар булуы аны саклап калган.***

Нижгар төбәгендә иң карт Аллаһы йортларының берсе булып торган Бозлауның тарихи мәчетендәге җомга намазыннан репортажны **5 биттә укыгыз.**

*Р.Сөннәтов фотосы.*



Бозлауның тарихи мәчете картлары җомга намазы алдыннан истәлеккә фотога төштеләр.

## Рухи тормышыбыз




tuganyak.ru

1990 елның 7 декабреннән башлап чыга

*Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!*

# Туган як

**№ 6** *(1250)*

**Җомга, 6 февраль 2015 ел**

*Бәясе ирекле*


## Сәяси караш

***Украинаның көньяк-көнчыгышында яңа көч белән башланып киткән хәрби хәрәкәтләрнең яңа корбаннары, андагы сәяси-социаль тотрыксызлык, бездә сумның бәясе төшү, Россиягә чит илләрнең санкцияләр салуы, илебезгә экономик кризисның янавы тирән борчуларга, кайгылы уйларга салсалар да, тормыш дәвам итә.***

***Глобаль сәясәттән тыш, бүген һәрберебез үз мохитында кайнарга, иң баштан үз проблемасын хәл итәргә тырыша, үзенә ышанып кына алга тырмаша. Мәсәлән, казы эшләп сатучыларга Рбишчада ат итенең кискен кыйммәтләнеп китүе тынгы бирми. Зур сату үзәге хуҗалары товарның сатылмавына зарлана. Сергач, Уразавыл базарларының да сыек булуы шул турыда сөйли.***

# Дөнья кая бара?

Ә авыл хуҗалыгы хезмәткәрләре билбауларын кыса төшеп язгы кыр эшләре кампаниясен кайгырта башлады инде. Алар җитештергән продукциягә тиешле хак һәм дотация булмаса да, борын астына сөйләнеп крестьян барыбер кырга чыгачак, чөнки ул җиргә беркетелгән һәм шушы язмышына буйсынган адәм баласы, игелекле хезмәт иясе. Иң авыр елларда Россияне нәкъ крестьян туендырган, аның какшамас тылын авыллар тәэмин иткән. Кызганычка каршы, бүген авылларның күбесе үлем түшәгендә яткан авыру картны хәтерләтә. Бу чирне безнең авылларга үзгәртеп кору җилләре йоктырды. Алла сакласын, хәзер менә бераз хәл була калса янсә санкцияләр белән Россияне тулаем буып куйсалар, аның таянычы да, ышанычы тылы да бүген юк әбәрендә. Дөрес, әлеге өлкә хөкүмәте һәм җаваплы түрәләр бу югалтуның нәрсәгә китерәчәген аңладылар кебек. Авылларга булышып та карыйлар, тик кирәкле нәтиҗәләргә генә һаман ирешеп булмый, терсәкне тешли алмаган кебек.

Авыл халкын югары түрәләр санга сукса, авылларның Россия өчен сәяси-социаль һәм икътисадый әһәмиятен абайласа, моннан берничә ел элек Сергач-Мәскәү поездын, ә бүген Сергач-Арзамас электричкасын монополистларга бетерергә ирек бирмәсләр иде. Димәк, үзгәртеп кору елларыннан алып бу йөк һаман шул урында кала бирә, чөнки авылларда күмәк хуҗалыклар юкка чыга бара, мәктәпләр ябыла килә, яшьләр шәһәргә кача...


Дөрес, 4 февральдә үткән хөкүмәт утырышында Владимир Путин бөтен электричкаларны кичектерми кире кайтаруны таләп итте. Россия Президентының бу боерыгы ничек үтәлгәнен вакыт күрсәтер.

Глобаль сәясәттән тыш узалдыңа дәүләт корып яшәүләре, күрәнегезчә, мөмкин түгел шул. Шушы глобаль сәясәтне океан артында тудыручылар бөек СССРны таркаттылар, хәзер Россиягә тынгы бирмиләр. Аның кайтавазы, кызганычка каршы, безнең якларга кадәр ишетелә, кесәләрдә тоела. Ә иң кызганычы – океан арты сәясәте безнең халык психикасында тискәре яңгыраш тапты: бер-беребезне усал эттәй чәйнәп бәрелек халәткә китерде, гомум тотрыклыкны, үзара дуслыкны юкка чыгарды. Менә монысы тәмам аяныч күренеш.

Бүген дөнья кая барганны әйтүе бик кыен. Украинадагы хәлләр аркасында Россиягә чыгарылган санкцияләр бер хәл, ә менә андагы сугыш хәрәкәтләре безнең территориягә үтеп керә башласа, аның ахыры нәрсә белән тәмамланачагы билгеле түгел. АКШ кулы белән башланган сугышлар бер генә илдә дә җирле халык өчен файдалы һәм кыска сроклы булмады. Алар башлаган кан кою күп җирдә бүген дә дәвам итә. Менә шуларыннан безне Алла сакласын. Тынычлык хакында казы ашарга түгел, сөяк кимерергә без риза. Бер үк сугышлары гына була күрмәсен. Ә бу куркыныч юк түгел...

**Олег ХӨСӘИНОВ.**

## Безнең белешмә



***Рәшит Гибәт улы НӘҖМЕТДИНОВ 1912 елның 15 декабрендә Казакъстанда урнашкан Актүбә шәһәрендә Түбән Новгород өлкәсе Красный Остров авылыннан эш эзләп килгән ярлы крестьян гаиләсендә туа. Биш яшендә ата-анасын югалта һәм ерак туганнарында тәрбияләнә. 1921 елда, ачлык вакытында балалар йортына эләгә.***

# Бәхетле саны «5»ле булган

1922 елда өлкән абыйсы Кави энесен үз янына Казанга ала. 1930 елда мәктәпне тәмамлагач, Рәшит Казан химия-технология институтының эзләнү факультетына укырга керә. Язучы абыйсы кулга алынганнан соң, Одессада яши, аннары Казанга кайта. 1937 елда Казан дәүләт педагогика институтының физика-математика факультетына укырга керә. Институтны 1940 елда тәмамлаганнан соң Кызыл Армия сафларына алына. Икенче Бөек Ватан сугышын "кече политрук" Нәҗметдинов Берлинда тәмамлый. Халыкара дәрәҗәдә шашка һәм шахмат остасы, СССРның атказанган тренеры, шахмат буенча биш тапкыр РСФСР чемпионы (1950, 1951, 1953, 1957, 1958 еллар), Татарстанның атказанган мәдәният эшлеклесе. Татар телендә шахмат уены турында беренче китап авторы, ә Казан шахмат мәктәбе Рәшит Нәҗметдинов исемен йөртә.

«Сабантуй мәйданыннан - Олимпия уеннарына» дип аталган китап 17 спорт төрендә дан казанган 48 татар һәм Татарстан спортчысының язмышын колачлый. Әйтик, автор китапта данлыклы шахматчы Рәшит Нәҗметдиновны беренче битеннән таныта. «һәр шахматчының бәхетле саны була. Рәшит Нәҗметдинов өчен андый сан — бишле. Ул биш тапкыр РСФСР чемпионы була, биш мәртәбә икенче урыннарны ала. Биш тапкыр СССР чемпионатының финалында уйный. Халыкара турнирларның бишесендә алгы урыннарга чыга. Дөньяның биш чемпионы белән уйнап, дүртесен ота, берсе белән уртак нәтиҗәгә килә», дип яза китап авторы.

**Интернеттан алынды.**

Кадерле укучыларыбыз, милләттәш-якташларыбыз истәлегенә **Сеченда үткән традицион районара шахмат турниреннан репортаж белән 4 биттә танышыгыз.**

## Өлкә яңалыклары

■ Богородск районында якын киләчәктә 3,5 мең башка исәпләнгән дүрт терлекчелек комплексы төзелү күздә тотыла.

■ Үткән елда Т.Новгород өлкәсенең эш белән тәэмин итү үзәгенә 97 899 кеше мөрәҗәгать иткән, шуларның 69 074е эшкә урнаштырылган. 31 декабрьгә эшсезлек дәрәҗәсе 0,49 процент тәшкил иткән.

■ 2014 елда җирле инициативаларга булышлык күрсәтү программасы өлкәнең 26 районында эшләгән һәм аның кысаларында 192 проект тормышка ашырылган. Шуларга 179,5 млн. сум акча сарыф ителгән. Шуның 100 млн. сумы өлкә, 51,1 млн. сумы район бюджетларыннан бүленеп бирелгән.

■ Өлкә прокуратурасы регионда азык-төлеккә ясалма рәвештә хакларны күтәрү очракларын ачыклаган. Тагын шундый фактларны билгеләр өчен өлкә антимонополия федераль хезмәте идарәсе кайнар линия ачкан. Әгәр дә сез азык-төлеккә хакларның сәбәпсез югары булуын күрдегез икән, шул турыда **8-950-360-20-50** телефон номерына шалтыратып белгертегез.

■ 8 февральдә Т.Новгородның Щелоково утарында традицион "Лыжня России – 2015" чаңгыда ярышу узачак. Анарда 5 меңгә якын спорт яратучы катнашыр дип көтелә. Белешмәләр өчен телефон: **8(831) 465-98-96.**

■ Регион буенча 2007 елдан башлап 130 000 гаилә ана капиталына ия булган.

■ Дәүләт Думасы депутаты Марат Сафин өлкә Законнар чыгару җыенында Яшьләр парламенты әгъзалары белән очрашты.

**Ильнар САДЕКОВ әзерләде.**

## Чын ирләр уены

# Сафаҗайда традиция дәвам итә

***Безнең авылда хоккей турнирлары оештыру күптән инде традициягә әверелде. Аның чираттагысы 1 февральдә узды. Бу юлы безгә кунакка Сеченнан "Факел", "Сергачтан "Район 45" командалары килде һәм Мәскәүдәге авылдашларыбыз кайтты.***

Турнирны оештыруда алдан зур әзерлек эшләрен авыл башлыгы Фәрит Каюмов, мәктәп директоры Рамил Мусин, физкультура укытучысы Рөстәм Хәйретдинов һәм мәскәүчеләр командасы капитаны Илдар Салахетдинов алып бардылар. Шулай ук бозны әзерләүдә хуҗаларның "Сафаҗай" командасы әгъзалары нык тырышты.

Шоба нәтиҗәсендә беренче булып бозга хуҗалар белән мәскәүчеләр чыкты һәм кунаклар җиңү яулады. Икенче уенда Сергач 3:0 исәбе белән Сеченны отып барса да, матч 4:5 исәбе белән тәмамланды. Шулай итеп өченче урын өчен хуҗалар Сергач белән очрашлар һәм 2:4 исәбе белән оттырдылар. Беренче урын өчен Сафаҗай мәскәүчеләре Сеченны 4:1 исәбе белән җиңде.

Бар командаларда грамотлар, медальләр белән һәм акчалата бүләкләнделәр. Ә җиңүче командага матур кубок тапшырылды, яхшы капкачылар дип Вахит Маликов (Мәскәү), Рушан Адиятуллин (Сергач), иң яхшы сакчы дип Александр Данилин (Сечен) һәм әйбәт һөҗүмче дип Наил Идрисов (Сафаҗай) табылды. Район Земство җыены депутаты Мирзаһләм Абдулганиев аерым бүләк белән сафаҗайлы Халит Гильмановны бүләкләде.

Бу турнирның спонсорлары булып Мөзәффәр Абдулбәров, Рөстәм Сабитов, Хасил Камалетдинов, Рафаэль Хафизов, Сафа Нуриманов, Зиннур Хамидуллин, Ваиз Зарипов, Хәмзә Махмутов, Рушан Якубов, Вельмир Каримов һәм Рафик Фехретдинов чыктылар.

Бу көнне йөзләгән җан атучы саф һавада мавыктыргыч хоккей карап ял итте, шул исәптә Петрякстан һәм Мочалидан хоккей сөючеләр дә бар иде.

**Рөстәм ХӘЙРЕТДИНОВ.**



*Алсу Багаутдинова фотосы.*

# КРЕСТЬЯННЫ җир ашата

***Белгәнебезчә, авылда яшәүче крестьянны игенчелек һәм терлекчелек ашата. Кайберләре аяк өстендә нык баскан күмәк хуҗалыкларда эшләп, ә кемнәрдер фермерчылык белән шөгыльләнеп көн күрә.***

*Фермерчылык*

Зур Рбишчада яшәүче Наил һәм аның улы Илгиз Алимовлар үзләренең ике йортларына бер булган "Наст" исемле КФХларына туры килгән 60 гектар чәчүлек җирләрендә иген, чөгендер, бәрәңге үстерәләр һәм ике фермада алты дистә баш мөгезле эре терлек асрыйлар. Алар ике гаилә булып төрле урамнарда яшәсәләр дә, хуҗалык эшләрен бергә алып баралар.

– Әле ярый әти бар, аның безгә ярдәме зур. Дөнья барышында шактый ук тәҗрибә туплаган кеше булырак, әтинең киңәшләре аеруча файдалы, - ди Илгиз Алимов.

Мин Илгизнең абзарындагы каралтысына кереп, терлекнең нинди шартларда торуын карап чыктым. Ул үз куллары белән бирегә суүткәргеч суздырган, һәр сыерның алдына су чүлмәге эшләп куйган. Тирес чыгара торган транспортер җайлаштырган һәм ферма эчендә үк чөгендер таптакыч агрегат урнаштырган. Каралтыга ялгап тегермән дә төзегән.

Улы Гаяз сабактан азат чакларында әтисе янында хуҗалык эшләрен башкарып мәш килә. Хәләл җефете Гөлнара үз фермаларында савымчы.

- Үзебезгә ярдәмгә көтүче яллар идек, тик хәзерге заманда 15-20 мең сум хезмәт хакына беркем дә моңа риза түгел, барчасына да зур акча кирәк. Шуңа күрә быел "электропастух" корылмасы сатып алырга ниятләнәбез. Терлекне ике йорттагы каралтыларда тотсак та, бер көтүдә йөртәбез. Кызганычка каршы, үзебез җитештергән продукциянең бәясе түбән, ә читтән китерелгән, киресенчә, зур бәягә куеп сатыла. Иген үстерү дә бит гади эш түгел, үзенә карата вакыт, тәҗрибә, белем таләп итә.

Чәчеләчәк орлыкның сыйфаты да, җирнең дымлылыгы да яхшы булырга тиеш. Киләчәктә мул уңыш алыр өчен көздән үк туңга сөреп, язын культивация эшләргә, тырмаларга һәм вакытында тукландырырга кирәк. Чәчтем дә, җиңелдән генә суктырып алдым түгел, - ди Илгиз. Ул үзе үк агроном да, механизатор да.



*Фермер әтисенә улы Гаяз булыша.*

Алга таба тагын ике каралты һәм бер зур амбар төзергә планнары бар икән, әлбәттә, өлкә программалары буенча. Соңгысында алган уңышны сакларга һәм техниканы тотарга урын әзерләмәкче булалар. Ангарның бер читенә иген киптергече эшләп куярга да исәпләре бар. Дәүләт тарафыннан ярдәм күрсәтелсә, шушы планнарны тормышка ашыру җиңелрәк булыр иде, заманча яңа техника да кирәк. Әмма иске техника белән дә югалып калмый Илгиз, ул ватылса, кырда ук үз куллары белән сафка куя.

Язын бакчалар чәчкән көннәрдә һәм җәй айларында печән әзерләүдә авыл халкына да ярдәмгә килә икән Илгиз. Йомыш белән килгәннәрне кире кайтарып җибәрми. Бакчасында ук умарталыклары да бар, димәк, балы үзенеке.

Нәтиҗә ясап әйткәндә: теләге һәм тырышлыгы булган кешегә авыл җирендә дә нужа тибәрергә мөмкинлекләр юк түгел. Кайбер яшьләр бер-берсеннән ишетеп әйтәләр дә бит: "Авылда берни юк, Мәскәүгә китәргә кирәк", - дип. Тик яхшы хезмәт хакы түләнә торган эш анда барчасына да "әлеп куймаган". Әлбәттә, "яңа заман" кешеләре зур акча турында хыялланырга ярата, ә зур акчалы, хәләл маллы эш тир түгеп, көч куюны таләп итә.

**Р.РАМАЗАНОВ.**
*Автор фотосы.*

*Районнарда*

## "Вести-Приволжье" Моклокада

**Спас районы**нда "Вести-Приволжье" телевизион программасының журналистлары килеп, районда җирле инициативаларга булышлык күрсәтә торган программа кысаларында тормышка ашырылган проектлар турында сюжет төшергәннәр. Алар Татар Моклокасында булып, шушы программа ярдәмендә ремонтланган җирле клубны караганнар, авыл башлыгы Салех Щегалев белән очрашканнар, клуб каршында эшләп килгән "Сәрвиназ" фольклор төркеме һәвәскәрләре һәм гади моклокалылар белән аралашканнар.

## Олы юлга беренче адым

**Кызыл Октябрь районы** үзәге Уразавылда урнашкан Пильна агропромышленность техникумының филиалында үткән атнада 21 студентка тантаналы рәвештә "Машинист-тракторчы" белгечлеге буенча дипломнар тапшырылган. Аларга алдагы тормышта уңышлар теләп, Пильна техникумы директоры Михаил Беспалов һәм милли район администрациясе башлыгы Халит Сөләйманов чыгыш ясаганнар.

## "5"ле өчен премия

**Пильна районы**нда ун ел инде район администрациясе башлыгы карары нигезендә мәктәпләрнең иң яхшы 9-11 класс укучыларына акчалата премияләр тапшырыла. Үткән ярты ел нәтиҗәләре буенча аңа 50 укучы лаек булган, шул исәптә Сафаҗайдан 14 һәм Петрякстан 4 укучы.

## Ветераннарны медаль көтә

**Кнәгеп районы** Ыргуда Ватанны яклаучылар көне алдыннан клубта Бөек Ватан сугышы ветераннарын хөрмәтләрләр. Кызганычка, сугышта катнашучылар бирегә калмаган инде, димәк, бу көнне бирегә унаты тыл ветераныңа Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан истәлекле медальләр тапшырылыр.

**И. ТОКТАРОВ** әзерләде.

*Авылларда*

- **Бозлау** администрациясе территориясендә ел башында ике янгын купкан.
- **Камка** мәктәбе укучылары арасында "Ел укучысы" конкурсы үткәрелгән.
- **Уразавыл**да 21 февральдә Равил Арифуллин истәлегенә һәм Ватанны яклаучылар көне уңаеннан домино буенча район турниры үтәчәк.
- **Зур Рбишча**дан сугыш ветераны Хайрулла Насибуллин, Суыксудан Абдулхай Миначев һәм Пашаттан Шафиятулла Хөснетдинов Ленинград блокадасын өзүнең 71 еллыгы уңаеннан Санкт-Петербург губернаторы тарафыннан ясатылган истәлек билгеләренә лаек булганнар.
- **Чүмбәли**нең кыр кулендә 20 февральдә Рөстәм Айдерханов истәлегенә биатлон буенча ярышлар оештырыла. Катнашырга теләүче барлык командалар да чакырыла. Чара 10.30 сәгатьтә башлана. Белешмәләр өчен телефоннар: 8-904-784-95-59, 8-831-94-2-14-07.
- **Кочко-Пожар** элемтә бүлегендә 17 февральдә Сергач почтамты «Туган як» белән берлектә "Абунәче көне" оештыра.
- **Татар Моклокасы** администрациясе Яңа ел уңаеннан биналарны бизәү буенча игълан ителгән район конкурсында бүләккә лаек булган.
- **Тукай** уртасында урнашкан күперне җирле инициативаларга булышлык күрсәтү программасы кысаларында ремонтларга планлаштыралар.
- **Ишавыл, Тукай, Бозлау** юлларын быел кардан фермерлар Зиннәтулла Мөхетдинов һәм Әнәс Азымов МТЗ-80 тракторлары белән арчыйлар.
- **Ыргу**лылар авыл урамнарын оператив рәвештә кардан арчыганы өчен җирле фермер Абдулхак Исхакова газета битләре аша рәхмәтләрен белдерә.
- **Шебиле**дә февральнең беренче көннәрендә күпләп яуган кардан көч-хәл белән арындылар.
- **Мәдәнә** мәктәбен, баларның күп өлеше грипп белән чирләү сәбәпле, бер атнага карантинга япканнар.
- **Суыксу**да янгын депосы булдыру эшләре тәмамланып килә.

**И. САДЕКОВ**
**әзерләде.**

*Конкурс*

## «Уңышлы ял көне фотосы»

Т.Новгород өлкәсенең экология министрлыгы аучылар һәм балык тотучылар өчен "Удачный снимок выходного дня" фотоконкурсы игълан итә. Ул өч номинациядә үтәчәк:

***- аудан фотоочерк;***
***- балык тотудан фотоочерк;***
***- пейзажлар.***

Конкурс актив яшәү рәвешен популярлаштыру һәм җәмгыять игътибарын флора белән фаунаны саклап калу проблемаларына тарту максаты белән үткәрелә.

Тулырак мәгълүматны министрлыкның рәсми сайтыннан **http://mineco-nn.ru/** белергә мөмкин.


**ИЗВЕЩЕНИЕ О ПРОВЕДЕНИИ ОБЩЕГО СОБРАНИЯ УЧАСТНИКОВ ДОЛЕВОЙ СОБСТВЕННОСТИ НА ЗЕМЕЛЬНЫЙ УЧАСТОК ИЗ ЗЕМЕЛЬ СЕЛЬСКОХОЗЯЙСТВЕННОГО НАЗАНАЧЕНИЯ, НАХОДЯЩИЙСЯ В ГРАНИЦАХ ЗЕМЕЛЬ СПК «ДРУЖБА»**

Кадастровым инженером Горлановым Николаем Анатольевичем
Почтовый адрес: Нижегородская область г.Сергач пос.Молодежный д.8 кв.69
**Адрес электронной почты**: 12345.68@bk.ru **Контактный телефон:** 8 (83191) 5-25-82
N квалификационного аттестата: 52-14-759
В отношении земельного участка с кадастровым N 52:45:0000000:3
Адрес (местонахождение): Нижегородская область, Сергачский р-н, тер в границах земель СПК «Дружба», тер. земли общей долевой собственности граждан, выполняются кадастровые по образованию земельного участка путем выдела в счет долей в праве общей долевой собственности из земель сельскохозяйственного назначения, расположенного примерно в 1500 метрах на юго-восток от д. Новая Берёзовка, Сергачского райна, Нижегородской области.
Заказчик кадастровых работ Устимов Василий Иванович
**Почтовый адрес:** Нижегородская область, Сергачский район,с. Акузово, ул.Школьная, д.64,кв.1
Контактный телефон: 8 9027857618
Собрание заинтересованных лиц по поводу ознакомления с Проектом Межевания земельного участка, образуемого путем выдела в счет долей в праве общей долевой собственности, состоится по адресу: 607510 Нижегородская область, Сергачский район, д. Новая Берёзовка, ул. Первомайская, д. 13а. «06» марта 2015 г. в 10 часов 00 минут.
С Проектом Межевания земельного участка можно ознакомиться в течении 30 дней со дня опубликования в СМИ по адресу: 607510 Нижегородская область, г. Сергач, ул. Ленинская, д. 42
Заинтересованные лица могут внести предложения о доработке Проекта Межевания земельного участка после ознакомления с ним по вышеуказанному адресу в течение 30 дней с момента опубликования в СМИ.
При проведении собрания по поводу ознакомления с Проектом Межевания при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы, подтверждающие права на соответствующий на земельный участок.
**Наши банковские реквизиты:**
р/сч 40602810942260100002 Волго-Вятский банк ОАО «Сбербанк России».
Доп. офис № 9042/0667 ВВБ СБ РФ. БИК 042202603. ИНН 5229002550. КПП 522901001
Счет на оплату выслать на электронный адрес: 12345.68@bk.ru
Почтовый адрес: 607510,г. Сергач, ул. Ленинская, д.42. **Телефон** 8 831 91 5-25-82.


# Замана белән бергә атлыйбыз

*«Туган як» һәм интернет*

***Китап яшәргә, фикер йөртергә өйрәтүче, сердәшче, киңәшче, рухи таяныч ул. Моны һәркайсыбыз яхшы аңлый, тик заманалар үзгәрә. Компьютерлар, планшетлар чоры дөньяны алгач, әлбәттә, китап, газета-журнал укучылар саны да шактый кими. Бүген күбесе кирәкле әсәрен, башка бербәр электрон гаджетлар аша интернет челтәренә кереп укуны кулайрак күрә.***

Замана таләп иткәч, ни итәрсең... Газета, журналлар, башка мәгълүмат чаралары да электрон вариантларын булдырырга мәҗбүр.

Арбадан бер төшеп калсаң, юлда югалуың бар, ди халык мәкале. Без дә "замана арбасы"ннан калышмаска булдык: өлкәнең татар телендә дөнья күрүче бердәнбер иҗтимагый-сәяси газетасы "Туган як" та Интернет челтәрендә үзенә лаек урын тапты. Бүген газетабызның **tuganyak.ru** сайты уңышлы гына эшләп килә.

Анда укучыны кызыксындырган язмалар урын ала. Интернет-газета рубрикаларга, сәхифәләргә, популяр язмаларга бүленгән. Газетада чыккан язмаларны шулар аша эзләп табарга мөмкин. Яңа санның язмалары, әлбәттә, сайтның баш битендә эленгән. Шулай ук бирегә укучыларыбыз аерым мәкалә уңаеннан аның авторына үзенең уй-тәкъдимнәрен җиткерә ала. Сайтта укучыларның үзара да фикер алышу мөмкинлеге бар.

Сайт эшләү дәверендә үзенә зур аудитория туплый алды: көн саен диярлек аның әчтәлеге белән уртача 120 интернет-кулланучы танышып бара. Ходайның рәхмәте белән якын арада бу сан тагын да арта төшәр дип ышаныса килә. Сайтның булуы – чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен зур сөенеч. Безнең сайтка керүчеләр буенча Чехия, Финляндия, Белоруссия һәм Франция илләре татарлары алдынгы урыннарда. Димәк, хәзер без дөньяның теләсә кайсы ноктасында яшәүче милләттәшләребез белән турыдан-туры аралаша алабыз. Без, үз чиратыбызда, сайтны даими яңарта, тулыландыра торабыз. Һәр җомга яңа материаллар куелган көнне сайтка керүчеләр саны ике йөздән арта. Әлбәттә, бу югары күрсәткеч.

**matbudat.ru** татар басма матбугатын берләштерүче портал-сайт белән дә тыгыз хезмәттәшлектә эшлибез. Анда татар газета-журналларында басылган иң яхшы язмалар белән танышырга мөмкин. Шул арада "Туган як" газетасында дөнья күргәннәре белән дә. Авторның фикере, яисә тулаем язма белән килешмәгән шәхесләр бирегә үз фикерләрен белдерә ала. Мәсәлән, безнең күзәтүебезчә, соңгы атналарда фикер уртаклашу өчен төп материал Ришат Рамазанов авторлыгында чыккан "Уттан качкан качкын" мәкаләсе булды.

Сүз тумышы белән Кызыл Октябрь районыннан булган, бүгенге көнгә кадәр Украинаның Луганск өлкәсендә яшәгән Рифкат Бәдретдинов турында бара. Тыныч кына яшәп килгән җиреннән туган авылы Семочкига качарга мәҗбүр булган милләттәшебез. Ул җирле түрәләрдән бернинди дә ярдәм булмаганына зарлана. Әлеге язманы укып, бу хакта үз фикерләре булганнар түбәндәгене яза.

Шөпшә (интернет челтәрдә билгеләнгән исем):

- Була дип яшәргә кирәк. Татар конгрессында эшләүчеләр бардыр, аларга да мөрәҗәгать итү кирәк. Шундый авыр вакытта да ярдәм итмәгәч, ул конгресснын кирәге бармы? Шулай үзара ярдәм итү өчен оештырылган бит ул.

Икенчесендә:

- Туганым, булмый инде булмагач – атаң урыс булмагач, Наташадан тумагач. Иванов Иван Иваныч булсаң, әллә кайчан инде безнең балаларга ипотекага бирелергә тиешле фатирны талап алып бирерләр, тиз арада документларыңны ясап, безнекеләрне кыскарту исәбенә эшкә дә урнаштырырлар иде, - дип яза "бөрчә" итеп танышкан башка берәү.

Соңгы вакытта интернет-укучы игътибарында булган тагын бер мәкалә - татар халкының алтын моң иясе Халидә Бигичева, аның тормышы, иҗаты турында дөнья күргән материал. Әлеге язманы сайтта караучылар саны бүгенгә ике мең тәшкил итә, ә бу хакта фикер уртаклашучылар саны сигез дистә. Калдырган комментарийларның күбесе диярлек Халидә ханымның дәртле, моңлы тавышлы булуы турында. "Айзирәк", мәсәлән, болай яза:

- Халидә ханымны бик яратам, хөрмәт итәм. Искиткеч талантлы җырчы. Аның җырлары йөрәкнең түренә үк үтеп керә. Үзенә генә хас тавыш, моң... Аңа исәнлек-саулык, бәхет, иҗади уңышлар теләп калам. Җырла, Халидәкәй, дәртле тавышың белән куандыр безне.

- Менә бу җырчы, ичмасам! Сирәк аның кебекләр. Чөнки соңгы вакытта шырдын-бырдын сикереп йөрүче җырчылар күбәеп китте. Ни тавыш, ни моң үзләрендә, - дигән башка берәү.

Ә менә "Мәрьям" болайрак яза:

- Халидә Бигичева кебекләр әллә каян килеп чыгалар да, шәп иттереп җырлап та күрсәтәләр. Ачкан авызыңны ябарга онытып ахырғача тыңлап утырасың.

Әлеге һәм башка материалларга комментарийлар белән алда күрсәтелгән сайтларда таныша аласыз. Моннан гайре, шунда ук үз фикерләрегезне, борчыган проблемаларыгызны да яза аласыз. Безнең сайтта сез шулай ук редакция белән элемтәгә чыгу номерлары, электрон почта адресларын да таба аласыз.

**Күргәнегезчә, "Туган як" газетасы да замана белән бергә атлый. Үз сайтыбызны булдыру, портал-сайт белән хезмәттәшлек итү - барысы да сезнең өчен эшләнә, кадерле укучыларыбыз.**

**Күптән түгел тагы да бер «балабыз» - электрон «Туган як» дөньяга аваз салды. Аны яздырып алучылар һәр җомга үз электрон почталарында яңа гына чыккан газетабызны укый алалар.**

**Бергә булыйк, бердәм булыйк!**

**Р.ХАМЗИНА.**

# Онытылган геройлар

1945-2015 Бөек Җиңүгә 70 ел

***Хәтер китабында 1923 елда Петрякста туган Азизов Абдулла Фатехович бар. Ул авыр тән җәрәхәтләреннән үлгән һәм 1944 елның 1 январенда Брянск өлкәсенең Суражск районындагы Кошелево авылы территориясендә җирләнгән. 262 нче укчылар дивизиясенең 950 нче полкы буенча 1944 елның 30 маенда чыккан приказ нигезендә ул СССРның Югары советы президиумы исеменнән “За боевые заслуги” медале белән бүләкләнә. Шушы приказда аның сугышчан батырлыгын кыскача тасвирлаган юллар да бар.***

“3 нче пулемет ротасы төзәүчесе, кызылармияче Азизов Абдулла Фатехович Дворище авылы районындагы бәрелештә үзен куркусыз сугышчы итеп күрсәтте. Станоклы пулеметның наводчигы буларак, дошманга төз һәм өзлексез ут яудыру аркасында безнең аерым подразделениеләрнең алга баруын тәэмин итте, гитлерчыларның ут нокталарын, тере көчләрен юкка чыгарды.

Архив документларында шулай ук Азизов (Азисов), Азимов, Азымов фамилияләренә, Каюм, Джафар, Алий исемнәренә караган бүләкләнү кәгазьләре дә бар. Әлбәттә, бу исем-фамилияләрдә хата китүе дә ихтимал. Ә менә аларның сугышчан батырлыкларында ялгыш булуы мөмкин түгел. Мәсәлән, 1919 елда туган Азизов Джафар Имаметдинович Кызыл армия сафларына К.Октябрь хәрби комиссариатыннан 1939 елның сентябрендә чакырыла. Беренче Украина фронты составында 1944 елның 21 июлендә контузия ала, хәлләнгәч тагын фронтка китә. 13 нче армиянең 50 нче аерым отрядында этләр җигемен (упряжка) йөртүче вазифасында хәрби бурычын үти.

“Кызылармияче Азизов Д.И. немец илбасарлары белән көрәштә үзен кыю сугышчы итеп күрсәтте. 1945 елның 28 январенда Одер елгасын кичкәндә аның көнбатыш ярында плацдармны киңәйтүдә, шулай ук Бобер, Квейс елгаларын кичкәндә барган сугышларда, Чибодорф авылы өчен бәрелештә кызылармияче Азизов дошманның көчле ут астыннан этләр җигемендә каты җәрәхәтләнгән 29 сугышчыны кораллары белән алып чыга. Шушы сугышчан батырлыгы өчен Азизов Д.И. “Кызыл Йолдыз” орденына лаек”, - диелгән 1945 елның 2 апрелендәге 1176 нчы укчылар полкы командиры һәм 350 нче дивизиянең баш табибы үтенечендә.

Шулай ук аның “Өченче дәрәҗә Дан” ордены белән бүләкләнүе турында да 1945 елның 11 июнендә приказ чыккан (№248-Н).

Якташ-милләттәшләремне **Өчкүл**дән тагын бер Хафиз исемле сугыш батыры белән таныштыруны үземнең бурычым дип саныйм.

Безнең якташлар Өчкүлдән чыккан сугыш батыры Хафиз Фаттахетдиновны яхшы белә. Әгәр бу адашларның туган еллары янәшә куйсак, алар Өчкүлдә бергә үскән яшьтәшләр булып чыга. Хафиз Җәфәров 1924 елныкы. Сугышка 1942 елның августында алына. Дошманга каршы 9 нчы гвардияле танк корпусының 17 нче аерым мотоциклы батальонында ефрейтор дәрәҗәсендә, мотоциклист-разведчик вазифасында сугыша. Аеруча сугышчан хәрәкәтләрдә 1943 елның маеннан алып, 1945 елның маена кадәр катнаша. 1944 елның 10 августында тән җәрәхәте ала. Савыгып чыкканнан соң үз подразделениесе сафына баса һәм Бөек Җиңүне Рейхстаг мәйданында каршылый. Сугышчан батырлыклары өчен иптәш Җәфәров “За отвагу” медале, икенче һәм өченче дәрәҗә “Дан” орденнары белән бүләкләнә.

Хенрардув шәһәрчегенә разведка ясау вакытында иптәш Җәфәров өч гитлерчыны атып үтерә, ә икесен пленга ала һәм шуның нәтиҗәсендә безнекеләр кыйммәтле мәгълүматларга тап була. Ә Бюхе торак пунктына разведкага чыкканда, Хафиз Җәфәровның мотоциклы немец автомашинасына тарый һәм якташыбыз югалып калмый – секунд эчендә шушы вакыйганы бәяләп ала һәм дошман автотранспортын юк итәргә дигән карарга килә. Әмма ләкин аның кузовыннан 20ләп гитлерчы агылып төшә башлый һәм алар каршы ут ача. Мотоцикл экипажы аларны да юк итә.

Марненфлекс торак пунктына да иптәш Җәфәров экипажы беренче бәреп керә һәм көтмәгәндә һөҗүм итү аркасында үзләреннән шактый күбрәк дошман көчен юк итә. Экипаж командиры шәхсән үзе 8 немец солдатын атып үтерә.

Өчкүл егете Хафиз Җәфәровның игътибарга лаек тагын бер батырлыгына тукталасым килә. 1945 елның 25 апрелендә ул Бухов-Карпцов кичү районының бер очында киртә-өем булуын ачыклый һәм бүтән разведчиклар белән шушы өем аша юл сала, безнең төп көчләр килгәнче аны дошманнан саклый, 14 немец солдатын юк итә...

Миндә булган мәгълүматлар буенча, безнең якташыбыз Хафиз Җәфәров Мәскәүдә Җиңү Парадында да катнашкан.

**Алек Җәфәров** 1925 елда туган. Татар, ВЛКСМ әгъзасы, Кызыл армия сафларына 1943 елның 10 январенда К.Октябрь район хәрби комиссариатыннан чакырылган. Дошманга каршы Беренче Украина, Ленинград һәм Белоруссия фронтларында сугыша, элемтәче кавалерист-фельдъегерь була. Штабларның даими күченеп торуына карамастан, ул төргәкләрне (приказларны) үз вакытында тапшырып килгән. Безнең бу якташыбыз да сугыштан җиңүче булып чыккан, әмма ләкин туган авылын махсус күрсәтмим. Аны балалары һәм оныклары танысыннар иде. К.Октябрь хәрби комиссариатына мөрәҗәгать иткән очракта, моны тиз ачыклап бирәчәкләр, чөнки анда грамоталы, ярдәмчел белгечләр эшли.

**Әббәс НАЗЕРОВ.**
Семочки-Мәскәү.
**(8-903-244-37-24).**

## Хакимият һәм без

### Проблемагыз булса, ЯЗЫЛЫГЫЗ

Губернатор һәм өлкә хөкүмәтенең гражданнарны кабул итү бүлмәсендә 18 февральдә 14.00 сәгатьтән башлап гражданнарны губернатор урынбасары Дмитрий Сватковский кабул итәр. Өлкә хөкүмәтендә ул сәламәтлекне саклау, мәгариф, мәдәният, спорт һәм эш белән тәэмин итү тармакларына кагылган сораулар белән шөгыльләнә. Өлкә түрәсенә сорау бирергә теләүчеләр моның өчен язу гаризасын һәм сорауга кагылган документларның күчермәләрен алдан тапшырырга тиешләр. Яныгызда паспорт булуы мәҗбүри. Кабул итүгә язылу ял көннәреннән гайре 11 февральгә кадәр һәр көн 9.00 сәгатьтән алып 18.00 сәгатькә кадәр, җомга көнне 9.00 сәгатьтән алып 17.00 сәгатькә хәтле, (Т.Новгород, Костин урамы, 2 йорт, 9 кабинет) барыр. Белешмәләр өчен телефоннар: 439-04-98, 430-96-39. Шулай ук губернатор һәм өлкә хөкүмәтенең гражданнарны кабул итү бүлмәсендә (Т.Новгород, Костин урамы, 2 йорт, 12 кабинет) 12 февральдә 14.00 сәгатьтән башлап пенсионерларга һәм льготалары булган гражданнарга хокукларны яклау буенча бушлай консультацияләр бирелер. Аларның сорауларына өлкә социаль сәясәт министрлыгы һәм дәүләт хокуклары департаменты белгечләре җавап кайтарыр. Белешмәләр өчен югарыда күрсәтелгән телефоннарга шалтырата аласыз.

## Игътибар!

### Автобуслар йөреше

Алдан язганыбызча, 1 февральдә Т. Новгородның Лядово мәйданында урнашкан “Нижегородский” автовокзалы ябылды. Сергач юнәлешендә йөри торган автобуслар хәзер “Сенной” автостанциясенә күчерелде һәм алар өлкә үзәгенә Родионов урамы аша, ягъни иске юлдан йөрер.

Ел башында Сергач-Арзамас-Сергач маршруты буенча йөргән электричка гамәлдән чыгарылды. Аның белән студентлар, шул исәптә татар егет-кызлары да Перевоз, Арзамас уку йортларына белем алырга йөри иде. Алар өчен мәсьәлә кискен тора әле. Шушы проблеманы өлешчә хәл итәр өчен Сергач автотранспорт предприятиесе шул юнәлеш буенча автобус маршруты оештырды. Сергач автовокзалыннан ул дүшәмбе көнне 5.15 сәгатьтә, җомга көнне 11.00 сәгатьтә, шимбә көнне 9.00 сәгатьтә кузгала, ә Арзамастан шул ук көннәрне 8.20, 14.00, 12.00 сәгатьләрдә юлга чыга. Ике якка да билет бәясе 317 сум. Шулай ук бу маршрут буенча шәхси транспорт та йөри.

**Үз хәбәрчебез.**

## Безгә язалар

### Активистлар очрашты

Чыгышлары белән Нижгар өлкәсе татар авылларыннан булган бер төркем активистлар 29 январьда Мәскәүнең Асадуллаев йортында очрашты.

Фикер алышканнан соң, агымдагы елга чаралар планы кабул ителде. Кайберләрен әйтеп тә китәргә була. Май бәйрәмнәре вакытында берничә авыл клубында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап концертлар, Рамазан аенда кайбер авылларда Ифтар мәҗлесләре оештырылыр.

Җәйге каникуллар вакытында татар командалары арасында Сергачта, Ураза-вылда яисә башка авылда футбол буенча чемпионат уздырылачак. Чемпионат барышында Россиянең танылган футболчылары белән мастер-класслар үткәрүе дә күздә тотыла.

Чираттагы очрашу 26 февральгә билгеләнде. Теләүчеләр булса, рәхим итегез! **Илдус АБДУЛЛИН, җыелыш сәркатибы.**
Уразавыл.

## Тарихи фото



1973 елның май аенда төшерелгән бу фотоны безгә Камкадан Мерхайдәр Мангушев китереп тапшырды һәм аңа кыскача гына аңлатма бирде.

Агымдагы алның 19 январенда 60 яшен билгеләгән Рәшит Сафаровны армиягә озату вакыйгасыннан бер мизгелне күрәсез. Безгә караган йөзләрдә шофер Мерхайдәрдән гайре сез тагын Жиһанша, Рәшит һәм Сәбит Аблязовларны, гармунчы Фатех Башкуровны, Харис Сафаровны, Шәмил Юхановны күрәсез. Болар барысы да “Яңа авыл” егетләре. Кызганычка каршы, Аблязовлар, Юханов безнең арада юк икән инде. Ә калганнары авылда яши.

## Подписка-2015

Кадерле укучыларыбыз! Февральдән «Туган як» газетасына агымдагы елның икенче яртысына әлеге бәяләр белән Сергач һәм К.Октябрь районнары халкы языла ала. Күргәнегезчә, сумның рәте кала бармый, шуңа алдан «Туган як»ка язылып куйсагыз, алдатмассыз.

**Редакция.**


**БУРЕНИЕ СКВАЖИН**
На артезианскую воду
**Тел.: 8 926 452 92 18,**
**8 985 991 53 42.** Реклама

**На заказ ДОСКА, БРУС, ШЛАКОБЛОКИ, ж/б ЗАБОРЫ.**
**ДОСТАВКА, ГАРАНТИЯ.**
Реклама **Тел.: 8 904 790 28 71.**

**ЗАКУПАЕМ** ДОРОГО
**ЛОМ** ЦВЕТНОГО МЕТАЛЛА
и б/у **АККУМУЛЯТОРЫ**
по адресу: г.Сергач, рядом с кафе «Уют».
Реклама **Тел.: 8 950 340 21 26.**


# Бушап калды күңелләр

## Хәтер-хатирә

*Туфрактан туган туфракка ук*
*Салынып да тәнең күмелер.*
*Үзе белән берни алып китмәс*
*Җир өстеннән киткән бу гомер.*

**К.Булатова.**

Әйе, Ходай Тәгалә җан иясенә гомер дигән бүләген үз үлчәме белән чамалап биргән. Берәүләр бала чакта, кемнәрдер үсеп буй җиткезгәч, кайсылары җимертеп дөнья куар чагында... Шул йөрәк өзгеч “вакытсыз” китүчеләр рәтендә олыгаеп, намазлар укып, уразалар тотып, дини кагыйдәләрне өйрәнеп, җеназасына кирәк-ярак әйберләрен үз кулы белән хәзерләп, үлем хаклыкны аңлап мәңгелеккә китүчеләр бездә бик күп. Атаклы җырчы А.Галимов җырындагыча, “...Китеп баргач – бушап калды бу дөньялар”. Дөньялар гына түгел, күңелләр бушап кала. Шундый да сөйкемле, мөлаем, ак яулыклы Хава апаның да (Нариманова-Әбельханова) бу дөньяны ташлап китүенә ике айга якын инде – 31 январьда 40 кичәсе иде.

Йөзеннән нур бөркеп торган Хава апа белән мәҗлесләрдә очрашкан саен 5-10 минут аулактарак ни булса турында сөйләшеп алу җаен табарга тырыша идем. Соңгы тапкыр безнең авылга мәҗлескә килгәч: “Кодача, әйдә мәчеткә өйлә укырга барыйк”, - дип миңа мөрәҗәгать итте. Ә безнең Рбишчада өйлә намазына хатын-кыз мәчеткә йөрми бит. Мин аңа:

- И, Хава апа, бездә бит өйләгә әбиләр йөрми, әйдә әнә теге бүлмәгә, шунда укырбыз, - дидем.

- Ә мин оланнарны ашыктырдым, бигрәк мәчетегезгә барасым килгән иде, ярар алайса, хәерлегә булсын, - дип ризалашты.

Хава апаның шундый тиз, тәһарәт алган чакта аяк өстеннән китеп баруын белгән булсам, әйдә, дигән булыр идем. Ике катлы зур мәчеттә безгә генә урын табылган булыр иде. Нинди зур үкенеч.

Ачлыкка чыдаган буын вәкиле ул. Ни барына шөкер кылып, яшәүдән ямь табып көн күрүче, аш-су, кием-салым кадерен белүче буын кешесе, сугыш чоры баласы.

Сафаҗай кызы Петрякстан Уразавылга район белән бергә килеп, Уразавылда ихтирам казанган шәхес.

Безнең халыкта, авылы башканың кауымы башка, диган бик гыйбрәтле әйтем бар бит әле. Шушы башка “кауым” сине үз итсен өчен кешедә уңай сыйфатлар булуы, кешелекле, ачык йөзле, туры сүзле, уңган куллы, зур ихтыяр көчле булуың бик мөһим. Кирәге чыкса үзеңне яклый белү дә сорала. Хава апада андый сыйфатлар, әлбәттә, булгандыр. Мәрхүмне соңгы юлга озатырга Уразавыл кешеләре генә түгел, тирә-як авыллардан да күп кеше килгән иде. Җеназасын алып киткәндә турыларында кара болыт кебек җыелган халык, яхшы кеше иде, урыны җәннәттә булсын, дип дога кылып калды.

Өч бала үстереп олы тормыш юлына чыгарган, җан юлдашын мәңгелеккә озаткач, тол хатын исеменә тап төшермәгән кешегә мин дә сабырлар дәрәҗәсендә булса иде, дип догага калам. Мәңгелек йортыбызга барыбыз да барасы, тик үзебездән соң яхшы исем, авылдашларыбыз, якыннарыбыз сагынып сөйләрди гамәлләр калдыралсак иде. Хава апа күңелләрдә менә шундый ак яулыклы, сөйкемле ак әби булып калыр. Бу язмам Абдылкотдус кызы Хава апаның рухына дога булып ирешсә иде.

**Н.ХӘСӘНОВА.**
Рбишча.

## Быел безгә 25!

Хөрмәтле газета укучыларыбыз, “Туган як”ның юбилейлы елына аяк бастык – агымдагы елның 7 декабрендә газетабызның дөнья күрүенә 25 ел тула. Чирек гасыр эчендә күпме материаллар бастырылган, аларда күпме кеше язмышы чагылган! Ул вакытта нинди проблемалар борчыган журналистларны һәм укучыларны, нинди актуаль темалар күтәрелеп чыккан, нинди сәхифәләр булган?

## Иске газета битләреннән

**1991 елның 8 февраль санының 1 нче битендә** Мөтеравылдан Али Фәхретдиновның язмасы урын алган. Ул **Анды**да һәм **Мөтеравыл**да күптәннән инде радио тапшырулары булмаганга зарлана. Мәскәүдән һәм бигрәк тә Казаннан тапшыруларны халык түземсезлек белән көткән. Тик 6 ел инде дәвам иткән үзгәртеп кору сәясәте нәтиҗәсендә гади халыкның үтенечләре күп очракта игътибарсыз калган.

Шулай ук **1 нче биттә** өлкә халык мәгариф бүлеге һәм РСФСР мәгариф министрлыгының хөрмәт грамоталары иясе, **Печә** мәктәбендә утыз елдан артык хезмәт иткән укытучы Нәфисә Исхак кызы Магҗанованың фотосы бастырылган. Аллага шөкер, Нәфисә апа әлегә исән, сигезенче дистәсен тутырып килә. Ул җирле “Нариманов” исемендәге СПК рәисе Сабир Магҗановның әнисе була.

Пильна районы **Сафаҗай** колхозының бер бинасында урнашкан Пильна азык комбинатының кондитер цехы эшләве турында **3 нче биттә** материал чыккан. Аны Надир Әббәсов җитәкләгән. Цехта шикәрле-баллы прәннекләр һәм печеньелар җитештергәннәр. Татлы тәм-томны авыл кызлары Ф. Нуриманова, К. Сираҗетдинова һәм авылның тагын дүрт кызы пешергән. Биредән район кибетләренә көн саен 700-850 килограмм яхшы сыйфатлы азык озатылган.

Цехның язмышы белән кызыксынып, без авыл башлыгы Фәрит Каюмовка мөрәҗәгать иттек. Аның әйтүенчә, ул предприятие күптән ябылган инде. Хәзерге вакытта аның бинасы да җимерелә бара икән.

**4 нче биттә** “Күренекле якташларыбыз” рубрикасы астында **Кече Рбишча**дан Бөек Ватан сугышында катнашучы Бәшәр Нурмөхәммәт улы Шәмшетдинов турында материал бастырылган. Туган авылының “Серп и молот” колхозында ул 35 ел дәвамында тракторчылар бригадасын җитәкләгән. Ул эшләгән елларда колхозда бөртекле ашлык уңышы 5-6 центнердан 32 центнерга кадәр үсә. 1990 елда бу сан 35,7 центнерга тиң була. Шул уңайдан колхозга күчмә Кызыл байрак тапшырылган. Кызганычка каршы, Бәшәр абый үткән елны вафат булды.

**5 нче биттә** “Әби-бабалар хәтере” дигән сәхифә әзерләнгән.

**6 нчы биттә** “Гаилә” рубрикасы астында **Петряксның** Сабировлар гаиләсе турында материал чыккан.

**7 нче биттә** тумышы белән **Шөбиле** авылыннан булган, ул вакытта Мәскәүдә яшәүче, шигърият яратучы Равил Азизов әсәрләре бастырылган. Һөнәре белән ул теш врачы иде, күптәннән вафат инде.

**Газетаның тиражы бу санда - 3250 данә. Язылу бәясе 10 айга 4 сум 33 тиен тәшкил иткән.**

**Илнар САДЕКОВ**
**күзәтеп чыкты.**

# Якташыбыз истәлегенә шахмат турниры үтте

*Күркәм гадәт*

***1 февральдә Сечен спорт комплексы бинасына Сергач, Сечен, Кызыл Октябрь һәм Пильна районнарыннан СССРның атказанган тренеры Рәшит Гибәт улы НӘҖМЕТДИНОВның истәлегенә багышланган шахмат турнирына өлкәннәрдән һәм яшүсмерләрдән торган командалар җыелды.***





ФОТОЛАРДА:
**- Нижгар татарлары конгрессы рәисе Гаяр Хәсәнов Сергач командасының яшь шахматчысы Эмиль Мөхәммәдьяровны (Шөбиле) бүләкли;**
**- шахмат такталары артында Пильна районы өчен чыгыш ясаган Сафаҗай шахматчылары К.Октябрь районының җыелма командасы белән очраша;**
**- турнирда катнашучыларны сәламләүчеләр Халит Сөләйманов, Гаяр Хәсәнов, Илдус Абдуллин, Алексей Кутырев, Зәки Валемеев, Максут Алимов һәм Кадрия Армиханова.**



Олы кунаклар арасында Сечен һәм Кызыл Октябрь районнарының җирле үзидарә башлыклары Алексей Кутырев һәм Халит Сөләйманов, өлкә татарлары конгрессы рәисе Гаяр Хәсәнов, РНКАТНОның Уразавылдагы даими вәкиллеге җитәкчесе Илдус Абдуллин, җирле район Земство җыены депутаты, Сечен агротехникумы директоры Вафа Айсин, Россия Федерациясенең атказанган физкультура хезмәткәре Зәки Валемеев, Сечен районының хөрмәтле гражданины Юрий Шекуров һәм Красный Остров авылы китапханәчесе Кадрия Армиханова бар иде. Турнирны бөек шахматчының авылдашы, Краснай авылы администрациясе башлыгы Максут Алимов тантаналы рәвештә ачып җибәрде һәм кунакларга сүз бирде.

Алар Рәшит Нәҗметдиновны күп яктан җылы сүзләр белән искә алдылар. Кадрия ханым Армиханова Рәшит Гибәт улының тормыш юлы турында кыскача сөйләп үтте.

Аннары түгәрәк система буенча 3 турдан торган шахмат турниры башланды. Яшүсмерләр арасында беренчелекне Сергач командасы яулады, икенчедә Сечен, өченчедә Кызыл Октябрь командалары булды. Ә өлкәннәр арасында җирле команда җиңеп чыкты, икенче-өченче урыннарга сергачлылар һәм кызылоктябрьлылар лаек булды.

Ике категориядә дә гомум команда нәтиҗәләре буенча Сергач командасы җиңүче дип табылды, икенчедә Сечен, кызылоктябрьлылар өченче булды. Пильна районы данын яклап килгән Сафаҗай авылы шахматчылары актив катнашучылар буларак билгеләнде.

Беренчелекне алучы ике команда Сечен районы хакимияте тарафыннан исемле кубоклар һәм дипломнар, призлы урыннарга ирешүчеләр мактау грамоталары белән бүләкләнделәр. Гаяр Хәсәнов һәм Илдус Абдуллин үзләренең иҗтимагый оешмалары исеменнән бүләкләр алып килгән иделәр. Халит Сөләйманов, үз чиратында, актив катнашучыларга һәм “җиңүгә омтылучы” дип табылган Кече Рбишча мәктәбе укучысы Нуршат Хәйретдиновка бүләкләрен тапшырды.

Турнирдан соң оештырылган табын артында Кызыл Октябрь районы командасы җитәкчесе Мирсат Диянов һәм тренеры Камил Хәйретдинов ярышларның әйбәт оештырылуын югары бәяләделәр, киләчәктә дә шундый чараларга җыелырга теләкләрен белдерделәр.

Турнирның төп иганәчесе һәм оештыручысы Максут Алимов РНКАТНО, өлкә татарлары конгрессы һәм Краснайдан “Якубов В.А.” КФХсы исемнәренә материаль ярдәм күрсәткәннәре өчен рәхмәтле.

**Ришат РАМАЗАНОВ.**
*Автор фотолары.*

# Тормыш - иң катлаулы мәдрәсә

*Имам сүзе*

***Менә икенче ел инде Аллаһының рәхмәте белән безнең “Нур аль–Ильм” дини уку йорты эшләп килә, анда 50гә якын шәкерт гыйлем ала. Хәзерге вакытта ике курс укучылары да үзләренең тырышлыгы һәм Аллаһының ярдәме белән кышкы сессия буенча имтиханнар тапшырдылар, күбесе яхшы билгеләргә. Шулар арасыннан 1 нче курстан иң яхшы укучылар исеменә Әнвәр Измаилов (Кочко–Пожар), Зәйтүнә Ситдикова (Пашат), Абдулкадер Идрисов (Шөбиле) лаек булдылар (фотода).***



Ә инде 2 нче курс укучылары арасында иң яхшы укучы исеме Рауза Хөсәиновага (Атяравыл), Әнәс Ситдековка (Яндавишча), Сания Кабеҗровага (Суыксу) бирелде.

Бу исемнәргә лаек булучыларны “Нур аль-Ильм” дини мәктәбенең укыту бүлеге тәбрик итә, укуларында зур уңышларга ирешүләрен теләп кала.

Әлбәттә, шушы дини уку йорты минем тормышымда бик зур урын алып тора, ул – йокысыз төннәрем, ул – минем юанычым да, куанычым да.

Әгәр юл йөрү кагыйдәләрен белмәгән кеше машина белән идарә итсә, аның нәтиҗәсе бик аяныч булырга мөмкин. Бүген исә бик күп кеше кирәкле канун-кагыйдәләрне өйрәнмичә, “тормыш” дигән машинада бара, кайберләре хәтта кайда “газ”, кайда “тормоз” булганын да чамаламый. Моны дини гыйлемнең кирәклегенә ишарә итеп әйтүем.

Безнең тормышыбыз үзенә күрә бер сынау, аны белем-сабак йорты белән дә чагыштырып була. Әйе, тормыш – иң катлаулы мәдрәсә. Без көн саен нәрсәдер эшлибез, нәрсәгәдер омтылабыз, шулай итеп Аллаһы каршында көн саен имтихан тотабыз. Үземә яхшы булсын дип, кемгәдер авырлык китерсәң, нинди дә булса проблемаңны хәл иткәндә хәрәмгә керсәң, ахирәт “зачёткасына” икеле куялар инде. Ә Кыямәт көнендә “Зур имтихан” булачак. Шуннан соң “зачётканы”, ягъни гамәл дәфтәреңне тоттыралар да, йә җәннәткә, йә җәһәннәмгә билгелиләр. Шуңа күрә без барыбыз да “тормыш” дигән мәдрәсәдә “укучы” шәкертләр. Имтиханнарны яхшырак биреп барыр өчен һәм Ахирәт көнендә бәхеткә һәм сәгадәткә ирешер өчен уку йортында гыйлем алырга, иманыбызны ныгытырга кирәк. Файдасы булмыйча калмас…

Үз динен өйрәнү һәрбер мөселманга фарыз булып йөкләнә. Шушы дини юлда хезмәт итүләребез риядан булмасын, бары тик Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы өчен генә булса иде. Безнең дини уку йортында белем алучы шәкертләр бу яктан уңай тәрбия алалар дип уйлыйм.

Әлбәттә, безнең дини уку йортында шәкертләребез төрле фәннәрдән гыйлем ала, гарәп телен һәм инде, иң мөһиме, Коръәни Кәримне укырга өйрәнә.

Шушы дини уку йортыбыз бүген Кызыл Октябрь районының горурлыгы булып санала. Ул озак кына еллар эшләсен һәм шәкертләр саны да артып торсын иде!

Аллаһы Раббыбыз һәркайсыбызга хәерле гомер, нык сәламәтлек, төпле гыйлем, кирәкле һөнәр кылып, илебезгә, динебезгә, милләтебезгә файдалы, әти-әниләребезгә миһербанлы-шәфкатьле булып яшәргә, тормышыбызда лаеклы урын табарга насыйп кылсын. Шуны онытмагыз: урын кешене түгел, кеше урынны бизи.

**Һәркайсыбызга Аллаһының кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып, динебезне куәтләүче булып яшәргә насыйп булсын.**

**Дамир хәзрәт КАЮМОВ,**
**“Нур аль-Ильм”**
**дини уку йорты җитәкчесе.**
*Автор фотосы.*

# Хәтер сандыгыннан

**Быел Бөек Җиңүгә 70 ел тула. Шул уңайдан исемдә калган берничә сугыш еллары вакыйгаларын "Туган як" газетасы укучыларына да җиткерәсем килде.**

## Самолет

1943 елның декабрендә Әсәнтау урамыбызның төньяк очына «кукурузник» самолеты төште. Аны карарга бөтен авыл халкы җыелды. Бу самолеттан күрше Масловка авылында туып-үскән Исибаев дигән рус кешесе чыкты. Ул нәкъ шул чорда Саратов өлкәсенең коммунистлар партиясе секретаре булып эшләгән. Аның әти-әнисе Масловкада яшәгән, әбисе, бабасы, туганнары да әле дөньяда булган.

Масловка тирәсендә тигез урыннар булмаганга күрә, самолет озак вакыт төшәргә урын эзләгән. Шул вакытта Исибаев яшь чакта әтисе белән күрше Ишавылга сабантуйга атлар чабышын карарга килгәнен исенә төшергән һәм очучыларга шунда утырырга кушкан. Исибаев белән бер очучыны чаналы атка утыртып Масловкага озаттылар, икенче очучы авылда самолетны сакларга калды. Шулай ук колхоз идарәсе дә самолетны каравылларга кешеләр куйды.

Икенче көнне иртән 10 сәгатьтә Масловкадан пар ат белән Исибаевны озата килделәр. Авыл халкының яше-карты мәйданга җыелды, Бозлаудан да күп килделәр.

Фронтка киткән ирләрнең әниләре, хатыннары, туганнары озак вакыт сугыштан язулар алмаганга күрә, хатлар тизрәк барып җитәр дигән өмет белән аларның яңаларын Исибаевка тапшырдылар. Минем әнием Зәйнәп тә әтигә хат язып аңа бирде.

Халык белән саубулашкач, Исибаев самолетка утырды һәм очкыч һавага күтәрелде. Ул мәйдан өстеннән бер мәртәбә түгәрәк сызды да, көнчыгышка таба юл тотты.

## Землянка

Сугыш елларын искә алганда, Ишавылдагы вышканы да язасым килә. Самолет төшкән урыннан ерак түгел шул ук тигезлектә һава һөҗүменә каршы вышка төзелгән иде. Аның янындагы землянкада солдатлар хезмәт итте. Ишавыл өстеннән очкан самолетларны күргәч, алар баскычлар буенча вышкага менеп, бинокль аша башка якынайта торган торбалар белән аларны карап, номерларын, маршрутларын рация аша каядыр белгертә иделәр. Солдатлар арасында Татарстаннан булган Миргазыйм исемле егет тә бар иде. Аның Әсәнтау урамы (әле Восточная) буйлап "Сарман"ны җырлап узганын ишеткәнем бар иде, Әминә исемле кызга гашыйк булганын да хәтерлим.

Әнием Зәйнәп кырдан ташыган салам белән шушы торакның, җир йортының мичен иртә-кич яга иде. Мин дә аның белән баргаладым. Шулай ук әни аларга Маньта коесыннан көянтә белән су ташыды. Солдатлар әнигә аеруча рәхмәтле булалар иде, бергәләп чәй эчкәннәре дә хәтеремдә. Авыл халкы солдатларны мунчага һаман чакырып торды. Хәтта Бәткән, Абдулгани, Апан мунчаларына кергәннәре исемдә тора.

## Ярдәм

Сугыш тәмамлангач, Ишавыл ирләре колхоз идарәсеннән рөхсәт сорап, читкә китеп эшлиләр иде. 6-8 кешелек бригадалар туплап, алар колхозларда, фермаларда ремонт ясап, яңа каралтылар төзеп йөрделәр. Эш хакын ашлык, ит белән, акчалата да ала иделәр.

Шундый бер бригада Саратов өлкәсендә ферма төзегән. Эшләре тәмамлангач, колхоз идарәсе эш хакын ашлыклата биргән. Капчыкларны автомашина белән пристаньга китереп, пароходка төямәкче булалар, ләкин пристань җитәкчесе моңа рөхсәт бирми. Югарыдагы инстанцияләрдән килгән документка таянып, Идел агымы буенча өстәрәк урнашкан өлкәләргә ашлык озату тыелган ул вакытта. Безнекеләр Хәмзә Үмәров җитәкчелегендә Саратов өлкәсенең таныш булган партия секретаре Исибаевка ярдәм сорап баралар. Ул аларны таный һәм бу мәсьәләне хәл итә.

Кеше башына икешәр тонна ашлык алып безнең ирләр туган авылларына кайттылар. Ә якташыбыз Исибаев соңрак Мәскәүдә ВЦСПСта илнең профсоюз башлыгы булып та хезмәт итте.

## Солдат

1945 елда безнең авыл егете Шафиулла Сөләйманов Германия территориясендә батырларча һәлак була. Аның хатыны Айнулхаят дүрт баласы (Мөнирә, Хәсән, Алимҗан, Фазылҗан) белән кала.

Унсигез яшен тутыргач, Шафиулла абзыйның малае Алимҗан хәрби бурычын ГДРда үти. Бирелдә ул әтисенең каберен эзләп таба, аны фотосурәткә төшереп әнисенә җибәрә. Авыл халкы бу фотоларны кызыксынып карый, чөнки барысы да Шафиулланы озын гәүдәле, таза ир, алдынгы колхозчы буларак яхшы белгәннәр.

Алимҗан хәрби хезмәтен тәмамлап авылга кайткач, Спас хәрби комиссариатыннан әтисенең каберен барып карарга юллама сорый һәм документлар туплап, әнисе, туганнары белән якын кешеләре җирләнгән урынга баралар, аны яд итәләр.

**Садек МАГҖАНОВ,**
**авыл старостасы.**
Ишавыл.

## *Менә сиңа мә!*

# Әбекәйләр типтерә

*Җан, диләр, йөрәк, диләр, татар халкы шулар уртасына күңел дигән серле дәрья урнаштырган. Кеше күңеле күзгә күренми, барлыгы белеми. Әмма ул бар. Күңел кеше белән бергә туа, бергә ярала, әле ул буш була, тора-бара тормыш тәҗрибәсе, хисләр, тәэсирләр, мәхәббәт белән байый. Күңелнең буш калу ихтималы да бар: бусы – кеше өчен иң зур фаҗига!*

**Аяз Гыйләҗев.**

Узган елда Казанда нәшер ителә торган газетаның 21 санында Кызыл Октябрь районында гомер итүче өч әбекәй турында мәкалә укыган идем. Вот молодец әбекәйләр, Татарстанга барып та югалып калмаганнар, үзләрен газетага зурлап язарлык итеп ихтирам яулаганнар. 84 яшьлек Әдлифә әби Хөсәинова, 82 яшьлек Һава әби Абдуллина, 81 яшьлек Сания әби Сафиуллина Татарстанның "Бәкер" шифаханәсендә сихәтләнгәннәр.

Һава әби белән Сания әби Семочкидан, Әдлифә әби Пашаттан икән.

«Телевизордан шушы шифаханәне бик мактагач, барып карыйсыбыз килде, авыл яшьләре интернет аша телефон номерларын табып бирделәр. Шалтыратып урыннар белештек. Казанга кадәр поездда, аннан таксида җилдердек.

Монда намаз укый торган бүлмә дә бар икән, шуңа бик сөендек. Җәлил хәзрәт Фазлыев белән бергә намаз укыдык. Ул безгә китапларын бүләк итте. Без бик канәгать. Сөенечебез чиксез. Дәвалану яхшы, тәмле ашаталар. Кызганыч, путевканы 10 көнгә генә алдык. Безнең якларда мондый хозурлык юк. Татарстанда тумаганга үкенеп тә куйдык. Хезмәткәрләр шул кадәрле игътибарлы, акчаң да җәл түгел. Әле тагын килергә исәбебез бар. Ходай язсын. Хөкүмәт уч тутырып өйгә китереп акча бирә, нигә рәхәтләнмәскә. Әдлифә әби 2011 елда, Һава әби 2013 елда хаҗ сәфәрендә дә булганнар икән.

Тормыш хәзер бик әйбәт, Ходайдан көн дә илгә тынычлык, муллык сорыйбыз», - дип сөйләгән әбекәйләр.

Менә бит нинди безнең оптимист әбиләр. Күңелләре киң, йөзләре ачык... Рәхмәт үзегезгә, хөрмәтле хезмәт һәм сугыш ветераннары. Татар тикле татарлар арасында сынатмапсыз.

**Сәкинә МУСИНА.**
Рбишча.


Магазин «ХОЗТОВАРЫ»
ДЕРЕВЯННЫЕ МЕЖКОМНАТНЫЕ ДВЕРИ И АРКИ ЛЮБЫХ ФОРМ И РАЗМЕРОВ.
ФИНСКАЯ ТЕХНОЛОГИЯ.
ПОКУПАЙТЕ И ЗАКАЗЫВАЙТЕ.
ВОЗМОЖНА ДОСТАВКА.
г. СЕРГАЧ, ул. ШКОЛЬНАЯ, д. 1 (около автовокзала).
Тел.: 8 909 282 05 00,
8 960 196 52 84.
Реклама



ИП САФИУЛЛИН Р.С.
имеет в продаже весь ассортимент пиломатериалов+ шпунтовка, вагонка, лестничные элементы...
Тел.: 8 904 922 90 47,
8 906 349 40 00.
Реклама



УСТАНОВКА, ПРОДАЖА И РЕМОНТ СПУТНИКОВЫХ АНТЕНН И ВИДЕОНАБЛЮДЕНИЕ.
Тел.: 8 920 030 55 55,
8 961 634 66 66.
Реклама


## *Авылдашлар*

# Ял белмәгән юбиляр

***Бик күпләр төрле бәйрәмнәрне ял итеп үткәрсә, сәүдә хезмәткәрләре шушы көннәрдә бөтенләй ял күрми диярлек. Февраль башында шундыйларның берсе - Кече Рбишча кибете мөдире Фаилә ханым Салахетдинова 55 яшьлек юбилеен каршы ала (фотода).***

Ул 33 ел дәвамында бар бәйрәмнәрне дә эш урынында уздыра, авылдашларына хезмәт итә. Авыл халкы арасында аның абруе зур һәм намуслы, эчкерсез, ярдәмчел, ачык йөзле булуына халык аны ярата. Юбиляр ханым белән бергә эшләүче Зөлфия Закирова һәм Зифа Хамидуллина да, мөдирләре кебек, кибеткә кергән һәр кешенең күңелен күрергә тырышалар.

- Без һәр авылдашыбызны үз күреп каршы алабыз, барлык сорауларына тулы җавап кайтарырга тырышабыз. Алар алырга теләгән нәрсә кибеттә булмаса, заказ белән китертәбез. Халык та безгә карата гел яхшы мөнәсәбәттә, - дип сөйләде хөрмәтле юбиляр. - Сатучылар Зөлфия һәм Зифа да үз эшләрен яратып, намус белән башкаралар. Коллективыбыз дус, берберебезне ярты сүздән аңлыйбыз дигәндәй, һаман уртак тел табабыз, киңәшеп эш итәбез. Шулай ук сельпо рәисе Рафек әфәнде Зәйнетдинов та бигрәк ярдәмчел җитәкче, даими рәвештә кибетне яңартып, җиһазландырып тора. Автомобиль белән товар ташучы Рәис Закиров та безне тыңлый, беркайчан да киреләнми, - ди елмаеп кына Фаилә апа.

Юбилярның кызы Зифа күптән инде авылда үз гаиләсе белән яши. Улы Нуршат әнисе янында, Сечен агротехникумында укый.

Хезмәттәшләренә кушылып, Фаилә апаны авылдашым булараk тәбриклим, аңа хезмәтендә уңышлар, нык сәламәтлек һәм озын гомер теләп калам. Сыңар канатын ачы тормыш җилләре каермасын, ә шушы җылы канат астында үсеп чыккан бала-оныклары гел шатлыклар белән генә сөендереп торсын иде газиз кешеләрен.



**Ришат РАМАЗАНОВ.**
Кече Рбишча.

***Ислам дине әүвәлдән үк татар халкының яшәү рәвешен билгеләгән. Аеруча изге кануннар авылларда яшәүче әби-бабаларыбыз көнкүрешендә зур урын алып торган. Ата-бабаларыбыз тау бите кебек тук, авылларда мәчетләр, мәдрәсәләр төзегәннәр. Нижгар ягының күбесе авылларында Алла йортларын төзүне гади халык үз өстенә алган. Кайберләрендә бу дини биналарны халле, күбесе очракта сәүдәгәр татарлар төзеткән. Үткән гасырларда шактый мәчетләр төзелсә дә, кызганычка каршы, бүгенгә кадәр сакланганнары аз. Сәбәбе - атеистик совет хөкүмәтнең 70 елга якын барган дингә каршы көрәше, әлбәттә. Шуңа да карамастан, кайбер авылларда тарихи мәчетләрне халык саклап кала алган. Шундыйларның берсе Бозлау авылында урнашкан. Узган җомга көнне нәкъ шушы Аллаһы йортына без юл тоттык.***

# Тарихи мәчетләрнең берсендә

## *Рухи тормышыбыз*

Ике катлы агач мәчете чиста, якты, җылы. Җомга намазын укырга шактый халык җыелган. Санамадым, ике дистәгә якын булса кирәк. Мәчет имамы Мөхәммәтша хәзрәт Мөбинов сүзе буенча, бу мәчеткә авылның бер өлешеннән генә картлар йөри. Ә Бозлау мөселманнарының дүрттән өч өлеше гыйбадәт кылырга яңа, таш мәчеткә бара. Шуны да әйтми кала алмыйм, Мөхәммәтша хәзрәтнең авылдашлары арасында абруе зур. Ул озак еллар җирле колхозны җитәкләп, авыл үсешенә гел ярдәм итеп торган, ә хәзер, мәхәллә җитәкчесе буларак, аның рухи тормышына уңай йогынты ясый. Бозлау авылының хөрмәтле гражданины да ул.

- Берничә ел элек мәчетнең ике йөз еллыгын билгеләп, зур мәҗлес оештырган идек. Анда авыл имамнары, өлкә, башкала дин әһелләре дә килгән иде. Бу мәчетнең тарихы ерак 19 гасыр башына карый. Аны 1811 елда Якуб исемле бай төзеткән. Халык сөйләгәрне Кыр Якубы диеп йөрткән. Бу чорда авылда ике мәчет булган. Кызганычка, бүгенге көнгә кадәр менә бусы гына сакланды, хәтта мәчетнең манарасы да киселмәгән иде. Моңа халык хәйләсе ярдәм иткән: җирле колхоз идарәсеннән авыл халкы мәчетне иген келәте булараk кулланыу сораган һәм шуның белән бинаны җимерелүдән саклап калган. Мәчетнең ике катында да ничәмә еллар иген сакланды. Үзгәртеп кору җилләре исә башлагач, без мәчетләрне кире торгызырга керештек. Җимерелгән икенче агач мәчете урынына 1994 елда яңаны төзеттек. Шушы елларда ук бу мәчетне дә торгыза башладык, капиталь ремонт ясадык, - дип сөйләде тарихи мәчет имамы.



Тиешле вакытта мәхәллә тигез сафларга басып, җыргә иман нуры чәчкән Җомга намазын укырга кереште, мәчеттә Коръән сүрәләре яңгырый... Изге вакыт, күңелләр яктыра, рух күтәрелә шушы мәлдә!

Намаздан соң мәхәллә таралырга ашыкмады. Танышттык, сөйләштек.

- Безнең төбәктә дингә караш бөтенләй үзгәрде бүген. Әлеге өлкә Диния нәзарәте идарәсе авыл мәхәлләләре тормышы белән кызыксынмый: килми дә, йөрми дә, намаз вакытлары турында информацияне дә бирми. Ярый әле "Туган як" газетабыз бар, һәр атна үзенең битләрендә шушы кирәкле информацияне бастырып килә. Бер еллык намаз вакытларын, дини бәйрәмнәрне туплаган брошюраны да бастырып, кирәк кешеләргә өләшә.

Безнең районда мөхтәсиб булмавы да эшне авырайта. Уйламагыз, кандидатлар юк түгел Спас районы имамнары арасында. Ләкин никтер алар берсе дә өлкә дини лидерына ошап җитми.

Узган елларда Диния нәзарәтенең элекке җитәкчесе безгә килеп вәгазь сөйли иде. Имамнарның квалификацияләрен арттыру, белемен агарту, яшь буынны дингә тарту эшләре дә актив алып барылды ул вакытта, - дип зарланды тарихи мәчет картлары.

Аллаһыбызга гыйбадәт кыла торган изге урын – мәчет, әлбәттә. Әмма безнең хак динебез мәчеттә генә түгел, гадәти көнкүрештә дә, мәдәнияттә дә, икътисадта да, урамда да чагылыш табарга тиеш. Бу эшләрне, миңа калса, мәчетләрдән, җирле имамнардан гайре өлкә Диния нәзарәте идарәсе дә алып барырга тиеш.

**Ринат СӨННӘТОВ.**

**Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ** (РОМАН)

# ГАМЬ

**Дәвамы.**
**Башы 48 нче санда.**

ӘҮВӘЛГЕ эш итеп, тикшерүче каравылчы картка кагылды. Ул сүзгә хирыс кеше булып чыкты. Керүченең кемлеге, нинди йомыш белән авылга килеп чыгуы турында кызыксынды.

- Мосафир мин, бабай. Үтеп барышлый гына, юл уңай бу авылга тукталдым. Кундырып чыгармаслармы дигән уй белән сезгә кергән идем, - дип җавап бирде егет.

- Урын җитәрлек анысы. Тик өйдә кандала дигән канэчкеч дошман бихисап. Төннәрен тәкатьне корыталар, - диде карт. Кандала хәзер дә тәнендә йөргән шикелле, күлмәк итәгеннән кулын кертеп аркасын кашып алды.

- Ул ягы яманрак икән шул, - диде керүче, хуҗаның хәленә керергә теләгәндәй, башын чайкап.

- Әйдә, утыр, берад тын ал. Сәфәрең арыткандыр, - дип карт ишек төбендәге бүкәннән урын күрсәтте. Утыргач, “юлаучы” сорады:

- Берьялгызың яшисеңме әллә?
- Карчык белән икәү бед.
- Балалар юкмы?
- Ике малаемның икесе дә фронтта.
- Үзең эшлисеңме?
- Селкенгән булам шунда.
- “Селкенү” ничек була инде ул?
- Каравыл торам.
- Фермадамы?
- Амбар саклаем мин.

- Бик җаваплы хезмәт икән бит, бабай. Куркыныч та. Бу заманда ни булмавы бар? Каракларның һөҗүм итүе дә ихтимал... Амбарларны күп басалар бит хәзер.

- Әйтәсе юк, улым. Күптән түгел үдебеднекен дә бастылар.

- Менә, әкәмәт!

- Әкәмәт шул. Элекке давхуд керде кичтән каравыл өенә. Бергә эшләдек бит. Сүләшеп утырдык. Тегенең бер шешә дәмдәм суы да барие. Шуны да чөмердек. Сафи кайтып китте, мин калай мич ягып калдым. Каравыл өе дә җылынган, мин дә оеганмын... Вәт шул. Минем чаманы белгәндә, төнлә келәтне дә басканнар. Исерек баштан каян сидәсең?

- Бурны тоттылармы соң? – дип кызыксынды егет.

- Каян тотсыннар инде? Эдли белүче дә, күрүче дә юк. Давхуд хатынны алып китеп, ябып яткырганнар иде, аны да чыгарганнар.

- Тикшерүчеләр синнән сораштылармы соң?
- Ничек кенә әле!
- Шушыларны сөйләдеңме?

- Кая инде! Сафи иртән: “Әгәр кичтән бергә эчкәнне ычкындырсаң, келәт басуда беднең икебедне гаепләячәкләр”, - дип кисәтте.

- Дөрес әйткән, - диде керүче, карт фикерен яклагандай итеп.

- Мин дә шул уйда...

...“Юлаучы” Сафетдин өенә шыпырт кына килеп керде. Хуҗа берьялгызы чәй эчеп утыра иде. Керүчене шәйләми калды, өстәлдәге балны да, түгәрәк кечкенә ипине дә яшерергә өлгерә алмады. Чакырылмаган “кунак”ның таныш-белеш түгел кеше икәнлеген чамалагач, бераз тынычлана төште. Үткән-сүткәннең аның ни ашавында, ничек яшәвендә нинди катнашы бар, янәсе... “Юлаучы” кунарга фатир юллап керүен әйткәч, күңел төбенә утырган хафасы гел юкка чыкты.

- Бүген үзем дә өйдә кунмыйм шул. Күрше авылдагы апаларга китәм, - дип сылтау тапты Сафетдин.

- Мондый хәлдә нишләмәк кирәк? Икенче берәүгә кагылып карыйм инде, - дип “юлаучы” чыгып китте һәм авыл советына килеп, Сафетдин хуҗалыгына тентүгә керү өчен, совет җитәкчесеннән пүнәтәйләр билгеләвен сорады...

...Сафетдиннең өй эчен, каралты-курасын, ихатасын бөртекләп күздән кичерделәр. Бер караштан, бернинди гаеп-кыек юк төсле иде, тик тәҗрибәле караш “юк”тан “бар” ясады. Өй базыннан он табылды, сарык ите тозлап кисмәккә салынган иде. Аны чолан астыннан чыгардылар. Бал бәрәңге бакчасындагы иске киртәләр астына савыт белән яшерелгән иде...

Эзләнү вакытында тикшерүченең кулына шикле кәгазь кисәге килеп эләкте. Анда: “Ачкыч кемнең кулында...” дип языла башланган иде. Почта тартмасына салынган язуның карламасы булырга тиеш. Егет шул фикергә килде һәм, кулъязманы төп нөсхә белән чагыштыру өчен, кәгазь кисәген үзе белән алды...

Хуҗалык мөдире хезмәтеннән баш тартып, амбар алдына аяк басмаска үз-үзенә сүз биреп кайтты Фәния тоткынлыктан. Өй ишеген ачып, эчкә атлаган гына иде, әйтерсең көтеп кенә торган, ялт итеп Хәлимә килеп керде.

- Исән-имин котылып кайтуың белән, малайкаем. Бүтән ул юлларны таптарга язмасын, - дип тезеп алды рәис.

- Рәхмәт изге теләгеңә, - дип җавап кайтарды хуҗабикә, авыр көрсенеп. Үзенең иректә икәнлегенә ышанып җитә алмый иде әле ул.

- Синең белән ничек кыланулары хакында сораштырып тормыйм, үз вакытың белән сөйләрсең әле, кимсетүләрсез, мыскыл итүләрсез булмый калмагандыр. Зәгыйфь зиһенле бәндә акылдан шашар урын шул ул, - диде Хәлимә, тоткынлык афәтләрен үз башыннан кичергән бәндә шикелле ачынып.

- Әйтәсе түгел, малайкаем! Дустыңа түгел, дошманыңа да күрсәтмәсен ябылу газапларын, - дип килеште Фәния.

- Бүген чыгарыңны ишеткән идем. Кайтып күренүеңне көтеп кенә тордым. Иртәгә иртүк районга җыелышка китәм. Амбар ачкычларын тапшырырга керүем, - дип, Хәлимә каеш бауга теркәлгән ачкычлар төргәген өстәл өстенә куйды. Бер ачкычларга, бер Хәлимәгә карап, Фәния фикерен ничек җиткерергә белмичә аптырап торды.

- Малай, мин бит амбар алдына бүтәнчә аяк басмам дигән нәзер белән кайттым. Башка кеше табарга туры килер, - дия алды ул шулай да.

- Бу хакта яңадан сөйләшербез. Бу минутларда гына икенче кеше таба алмыйм бит инде. Идарә утырышына куймыйча торып, сине эштән азат итеп булмый... Эшләү ягын кара әле син. Дошманнарны сөендермә. “Гаебе булган аның, югыйсә китмәс иде”, - дип артыңда чәйнәнеп йөрмәсеннәр.

- Анысы шулай да... Адәм хурына калдырдылар бит. Авылда күренү дә оят сыман миңа хәзер... Ярый әле икенче тикшерүче килеп...

- Беләм. Аны Әхмәт Хаҗиевич чакырттырды. Син түгел, Габсаттарлар, НКВД түрәләре үзләре адәм көлкесенә калды. Районнан очыртмакчылар аларны. Белеп тор: андыйлар өчен дә закон бар...

Бу сүзләрне ишеткәч, Фәниянең күңеле йомшый төште. Иң баш түрәләр дә гаепсез икәнлеген белгәннәр, аңа ышанганнар икән ләбаса...

- Эчкерсез рәхмәтемне җиткерәсем бар икән әле Әхмәт Хаҗиевичка, - диде Фәния, уйчанлана төшеп. – Минем ише гадиләр турында да кайгырткач, асыл бәндәләрнең берсе икән.

- Ул озакламый килергә тиеш, рәхмәтеңне шунда әйтерсең, - диде дә, кергәндәге шикелле капылт кына чыгып та китте Халимә.

...Фәния казан астына ут тергезде, кайнатырга су куйды. Хафалы юлдан кайткач, тынычлана төшеп чәй эчеп алу иде исәбе. Әмма өйдә авызга кабып чәйнәрлек тәгам ризык юк. Ярый бәрәңге бар. Җәһәт-җәһәт кенә юып, аны казан артындагы чүлмәккә салды. Күбрәк итте. Кемдер килеп керер сыман тоелды аның күңеленә. Әлбәттә инде, Сафасын көтте. Кайтарып җибәрәләр, дип байтактан хәбәр салган иде, ни өчендер озаклады. Хәбәр-хәтере дә юк ичмасам...

Фәниянең кимсетелгән күңеленә янәдән моңсулык өстәлде. Берьялгызы бер өйдә. Янда сүз алышырлык җан иясе юк. Ашыйсыны китереп, бәрәңге исе өйдә таралгач, хатын уйларыннан арына төште. Суын сыккач, чүлмәкне пешергән урынга кире утыртып, эчендәге калдык суны саркытып алды да, бәрәңгенең бераз өлешен агач табакка салып, өстәлгә куйды. Кыздырылган кишер кисәкләреннән чәй пешерергә йөргәндә, кинәт кенә өй ишеге ачылды. Кабаланып кереп килүче малай нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан иде, өлгерә алмый калды, бусагага абынып, эчке якка тәгәрәде. Фәния җәһәт кенә килеп малайны күтәрде дә сорады:

- Нәрсә булды, улым? Бу тикле нигә кабаланасың?

- Фәния апа!.. Сафа... Сафа абзый кайта... Титаклап безнең очтан үтте, - дип сүзләрне йотайота, ашыгу сәбәбен көч-хәл белән аңлатты малай.

Сөенечле хәбәр китерүче малайга ике йомырка тоттырды да аның артыннан үзе дә урамга чыкты. Ике култык таягына асылынып, аркасына солдат капчыгы кигән Сафа, титаклый-титаклый атлап, үзләре турына якынлашып килә иде. Фәния йөгереп барып ирнең муенына асылынды. Күкрәгенә башын куеп, кимсетүләр кичереп тә акмаган күз яшенә ирек куйды. Сабый балаларча ярсып елады. Аркасыннан сыпыра-сыпыра, Сафа аны тынычландырырга тырышты.

**Дәвамы бар.**

## Казан күрсәтә

### Дүшәмбе, 9 февраль

05:00, 17.00, 19.00 Татарстан хәбәрләре. 12+ 05:10, 02.00 «Җомга киче». Концерт. 12+ 06:00 «Манзара». 6+ 08:00, 14.00, 18.30 Новости Татарстана. 12+ 08:10 «Народный будильник». 12+ 09:00, 00.30 «Московская сага». Телесериал. 12+ 10:00, 17.20 «Ике йолдыз». Телесериал. 12+ 10:55 «Дин вә хәят». 6+ 11:00 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт. 0+ 11:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+ 12:00, 22.00 «Хиромант». Телесериал. 12+ 13:00 «Семь дней». 12+ 14:15 «Закон. Парламент. Общество». 12+ 14:55 «Тиззарядка». 0+ 15:00 «Хочу мультфильм!» 0+ 15:15 «Күчтәнәч». 0+ 15:30 «Тамчы-шоу». 0+ 15:55 «Җырлыйбыз да, биибез». 0+ 16:05 «Волшебное дерево». Телесериал для детей. 0+ 18:05 «Переведи! Татарча өйрәнәбез». 6+ 19:30 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «СКА» (Санкт-Петербург) - «Ак Барс» (Казань). 12+ 23:00 «Морпехи». Телесериал. 16+ 00:00 «Видеоспорт». 12+ 01:20 «Тамак». Телесериал. 16+

### Сишәмбе, 10 февраль

05:00, 17.00, 21.30 Татарстан хәбәрләре. 12+ 05:10, 02.00 «Мәдәният дөньясында». 12+ 06:00 «Манзара». 6+ 08:00, 14.00, 18.30 Новости Татарстана. 12+ 08:10 «Народный будильник». 12+ 09:00, 00.30 «Московская сага». Телесериал. 12+ 10:00, 17.20 «Ике йолдыз». Телесериал. 12+ 11:00 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт. 0+ 11:30 «Туган җир». 12+ 12:00, 22.00 «Хиромант». Телесериал. 12+ 13:00 «Секреты татарской кухни». 12+ 13:30 «Размышления о вере. Путь к исламу». 6+ 13:35 «Путь». 12+ 14:15 «Музыкаль каймак». 12+ 14:55 «Тиззарядка». 0+ 15:00, 21.00 «Хочу мультфильм!» 0+ 15:15, 21.15 «Күчтәнәч». 0+ 15:30 «Яшьләр тукталышы». 12+ 15:55 «TAT-music». 12+ 16:05 «Волшебное дерево». Телесериал для детей. 0+ 18:05 «Переведи! Татарча өйрәнәбез». 6+ 19:00 Волейбол. Европейская лига чемпионов. Женщины. «Динамо-Казань» - «Вакифбанк» (Турция). 6+ 23:00 «Морпехи». Телесериал. 16+ 00:00 «Грани «Рубина». 12+ 01:20 «Тамак». Телесериал. 16+

### Чәршәмбе, 11 февраль

05:00, 17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре. 12+ 05:10, 02.00 «Җырлыйк әле!» 6+ 06:00 «Манзара». 6+ 08:00, 14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+ 08:10 «Народный будильник». 12+ 09:00, 00.30 «Московская сага». Телесериал. 12+ 10:00, 17.20 «Ике йолдыз». Телесериал. 12+ 10:55 «Дин вә хәят». 6+ 11:00 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт. 0+ 11:30 «Халкым минем...». 12+ 12:00, 22.00 «Хиромант». Телесериал. 12+ 13:00 «Среда обитания». 12+ 13:30 «Легенды дикой природы». Документальный фильм. 6+ 14:20 «Әдәби хәзинә». 6+ 14:55 «Тиззарядка». 0+ 15:00, 21.15 «Хочу мультфильм!» 0+ 15:15, 21.00 «Күчтәнәч». 0+ 15:30 «Без - Тукай оныклары». 0+ 15:45 «Һөнәр». 6+ 15:55 «Җырлыйбыз да, биибез». 0+ 16:05 «Волшебное дерево». Телесериал для детей. 0+ 18:05 «Переведи! Татарча өйрәнәбез». 6+ 19:15 «Трибуна Нового Века». 12+ 20:30 «Татарлар». 12+ 23:00 «Морпехи». Телесериал. 16+ 00:00 «Видеоспорт». 12+ 01:20 «Тамак». Телесериал. 16+

### Пәнҗешәмбе, 12 февраль

05:00, 17.00, 20.00 Татарстан хәбәрләре. 12+ 05:10, 02.00 «Башваткыч». 12+ 06:00 «Манзара». 6+ 08:00, 14.00, 18.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+ 08:10 «Народный будильник». 12+ 09:00, 00.30 «Московская сага». Телесериал. 12+ 10:00, 17.20 «Ике йолдыз». Телесериал. 12+ 11:00 «Онытa алмыйм». Ретро-концерт. 0+ 11:30 «Без тарихта эзлебез». 6+ 12:00, 22.00 «Хиромант». Телесериал. 12+ 13:00 «Черное озеро». 16+ 13:30 «Легенды дикой природы». Документальный фильм. 6+ 14:15 «Размышления о вере. Путь к исламу». 6+ 14:20 «Әдәби хәзинә». 6+ 14:55 «Тиззарядка». 0+ 15:00, 21.15 «Хочу мультфильм!» 0+ 15:15, 21.00 «Күчтәнәч». 0+ 15:30 «Мәктәп». 0+ 15:45 «Көлдермеш». 6+ 15:55 «Җырлыйбыз да, биибез». 0+ 16:05 «Волшебное дерево». Телесериал для детей 0+ 18:05 «Переведи! Татарча өйрәнәбез». 6+ 19:15 «Трибуна Нового Века». 12+ 20:30 «Татарлар». 12+ 23:00 «ТНВ: территория ночного вещания». 16+ 00:00 «Автомобиль». 12+ 01:20 «Тамак». Телесериал. 16+

### Җомга, 13 февраль

05:00, 17.00, 21.30 Татарстан хәбәрләре. 12+ 05:10 «Татарлар». 12+ 05:30, 11.00 «Нәсыйхәт». 6+ 06:00 «Манзара». 6+ 08:00, 14.00, 18.30 Новости Татарстана. 12+ 08:10 «Народный будильник». 12+ 09:00, 00.30 «Московская сага». Телесериал. 12+ 10:00, 17.20 «Ике йолдыз». Телесериал. 12+ 10:50 «Җомга вәгазе». 6+ 11:30 «Белем дөньясы». 6+ 12:00 «Легенды дикой природы». Документальный фильм. 6+ 13:00 «Актуальный ислам». 6+ 13:15 «НЭП». 12+ 13:30 «Дорога без опасности». 12+ 13:40 «Реквизиты былой суеты». 12+ 14:20 «Аулак өй». 6+ 14:55 «Тиззарядка». 0+ 15:00 «Хочу мультфильм!» 0+ 15:15, 21.15 «Күчтәнәч». 0+ 15:30 «Твои новости» (Univer-TV). 6+ 15:45 «TAT-music». 12+ 16:00 «Яшьләр on-line». 12+ 18:05 «Татар халык җырлары». 0+ 19:00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак Барс» - «Лада» (Тольятти). 12+ 22:00 «Спорт тайм». 12+ 22:30 «Глаза». Художественный фильм. 12+ 01:20 «Тамак». Телесериал. 16+ 02:00 «Җомга киче». Концерт. 12+

### Шимбә, 14 февраль

05:00 «Глаза». Художественный фильм. 12+ 06:30, 18.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+ 06:45 Татарстан хәбәрләре. 12+ 07:00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+ 09:00 «Секреты татарской кухни». 12+ 09:30 «ДК». 12+ 09:45 «Поем и учим татарский язык». 0+ 10:00 «Музыкаль дистә». 12+ 11:00, 02.00 «Әдәби галәмгә тәрәзә...». Тәнкыйтьче Фәрвәз Миңнуллин истәлегенә багышланган телеочерк. 6+ 12:00 «Халкым минем...». 12+ 12:30 «Видеоспорт». 12+ 13:00 «Әдәби хәзинә». 6+ 13:30 «Татар халык җырлары». 0+ 14:00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+ 14:30 ТВ фондыннан. «Илһам булганда...». 6+ 16:00 «Татарлар». 12+ 16:30 «Родная земля». 12+ 17:00 «Белем дөньясы». 6+ 17:30 «Каравай». 6+ 18:00 «Среда обитания». 12+ 19:00 «Башваткыч». 12+ 20:00 Татарстан. Атналык күзәтү. 12+ 20:30 «Җырлыйк әле!» 6+ 21:20 «Страхование сегодня». 12+ 22:00 «Валентинка». Художественный фильм. 16+ 00:00 «Проклятие золотого цветка». Художественный фильм. 16+

### Якшәмбе, 15 февраль

04:50, 00.00 «Красная шапочка». Художественный фильм. 12+ 06:30 Татарстан. Атналык күзәтү. 12+ 07:00 «Sиңа Миннән Sәлам». 6+ 09:00 «Мәктәп». 0+ 09:15 «Тамчы-шоу». 0+ 09:45 «Поем и учим татарский язык». 0+ 10:00 «Яшьләр тукталышы». 12+ 10:30 «Музыкаль каймак». 12+ 11:25 «Муса Джалиль. Возвращение поэта». Телефильм. 6+ 11:50 «Дорога без опасности». 12+ 12:00 «Автомобиль». 12+ 12:30 «Секреты татарской кухни». 12+ 13:00 «Әдәби хәзинә». 6+ 13:30 «Татар халык җырлары». 0+ 14:00 «Закон. Парламент. Общество». 12+ 14:30 «Татарлар». 12+ 15:00 «В мире культуры». 12+ 16:00 «Караоке татарча». 6+ 16:30 «Видеоспорт». 12+ 17:00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак Барс» - «Нефтехимик» (Нижнекамск). 19:30 «Черное озеро».16+ 20:00 «Аулак өй». 6+ 20:30 «Хөршидә-Мөршидә» кунак җыя». 12+ 21:00 «Семь дней». 12+ 22:00 «Музыкаль дистә». 12+ 23:00 «Яшьләр on-line». 12+ 01:45 ТВ фондыннан. «Илһам булганда...». 6+

## НАМАЗ-ҖӘННӘТ АЧКЫЧЫ

| февраль | Иртәнге | | Өйлә | Икенде | | Ахшам | Ястү |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | башы | кояш чыга | | башы | ахыры | кояш бата | башы |
| 9 Дүш | 6:06 | 7:36 | 12:30 | 15:16 | 16:44 | 16:49 | 18:19 |
| 10 Сиш | 6:04 | 7:34 | 12:30 | 15:18 | 16:46 | 16:51 | 18:21 |
| 11 Чәрш | 6:02 | 7:32 | 12:30 | 15:20 | 16:49 | 16:54 | 18:24 |
| 12 Пәнҗ | 6:00 | 7:30 | 12:30 | 15:21 | 16:51 | 16:56 | 18:26 |
| 13 Җом | 5:58 | 7:28 | 12:30 | 15:23 | 16:53 | 16:58 | 18:28 |
| 14 Шим | 5:55 | 7:25 | 12:30 | 15:24 | 16:55 | 17:00 | 18:30 |
| 15 Якш | 5:55 | 7:23 | 12:30 | 15:25 | 16:57 | 17:02 | 18:32 |

Өлкә Диния нәзарәтеннән алынды.

